**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге составына керүче Адав-Толымбай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләр турында**
**КАРАР**

01 ноябрь 2023 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Адав-Толымбай авылында юлларны төзекләндерү, зиратларны төзекләндерү, кышкы чорда юлларны кардан чистарту, часовня территориясен төзекләндерү эшләрен башкару өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2023 елның 1 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә 630 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 330 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 320 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 10 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлеге составына керүче Адав-Толымбай авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.
2. «Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Адав-Толымбай авылында юлларны төзекләндерү, зиратларны төзекләндерү, кышкы чорда юлларны кардан чистарту, часовня территориясен төзекләндерү эшләрен башкару өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.
3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Адав-Толымбай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________А.Ф. Әхмәтҗанов

Адав-Толымбай авыл җирлеге
башлыгы __________________ А.Ф. Әхмәтҗанов